ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 гыйнвар 2026 ел № 53

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Билгеләргә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына сатуларны оештыручы итеп Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеген;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына аукцион үткәрү буенча вәкаләтле орган итеп Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеген;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына шартнамә төзү һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту буенча вәкаләтле орган итеп Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсен.

3. Үз көчен югалткан дип таныrга:

1) Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы Карары;

2) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның 2017 елның 18 апрелендәге 2342 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 23 гыйнварындагы 251 номерлы Карары;

3) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 26 мартындагы 2090 номерлы Карары;

4) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 23 июлендәге 4940 номерлы Карары;

5) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 апрелендәге 2274 номерлы Карары;

6) Башкарма комитетның «Башкарма комитетның 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 августындагы 6957 номерлы Карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге башлыгы Л.Р. Бикташевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                        Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 13 гыйнварындагы
53 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын
урнаштыру тәртибе турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруны тәртипкә салу, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкына сәүдә хезмәте күрсәтүне оештыру һәм аның сыйфатын яхшырту өчен шартлар тудыру максатында эшләнде.

2. Әлеге Нигезләмә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен һәм нигезләрен билгели һәм киосклар, павильоннар урнаштыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

3. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары күчемсез милек булып саналмый һәм техник исәпкә кертелергә тиеш түгел, аларга хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлергә тиеш түгел.

4. Әлеге Нигезләмәдә күздә тотылган таләпләр вакытлыча характерга ия бәйрәм, иҗтимагый-сәяси, мәдәни-массакүләм һәм спорт-массакүләм чаралары үткәргәндә, ярминкәләр, күргәзмә-ярминкәләр үткәргәндә стационар булмаган сәүдә объектлары урнаштыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

2 бүлек. Төп төшенчәләр һәм аларның билгеләмәләре

5. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) ваклап сату – шәхсән, гаиләдә, йортта һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле булмаган башка максатларда файдалану өчен товарлар сатып алу һәм сату белән бәйле сәүдә эшчәнлеге төре;

2) сәүдә субъекты – сәүдә белән шөгыльләнүче һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат;

3) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан эшләнгән һәм расланган, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарын һәм аларда сатыла торган товарлар, күрсәтелә торган хезмәтләр төркемен билгеләүче хокукый акт;

4) сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты – капиталь төзелеш объекты һәм күчемсез милек булып саналмаган, инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташкан яки тоташмаган (технологик кушылу) булуга бәйсез рәвештә җир участогына ныклап тоташтырылмаган корылма яки конструкциядән гыйбарәт сәүдә объекты, шул исәптән ел сезоннарында урнаштырыла һәм күчереп йөртелә торган корылма (урамга

ташып сәүдә итү өчен күчереп йөртелә торган чаралар, бакча культуралары мәйданчыгы, чыршы базарлары һәм башкалар);

5) сәүдә автоматы – сатучы катнашыннан башка товарлар сату (хезмәтләр күрсәтү) өчен билгеләнгән техник корылма яки конструкция;

6) бакча культуралары мәйданчыгы – бакча культуралары сату өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган конструкция;

7) чыршы базары – табигый ылыслы агачлар сату өчен мәйданчыктан гыйбарәт махсус җиһазландырылган вакытлы конструкция;

8) күчереп йөртелә торган корылмалар (күчереп йөртелә торган сәүдә объектлары) – автокибетләр (автолавкалар, автоприцеплар), изометрик сыешлыклар һәм цистерналар, арбалар, лотоклар һәм сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен башка махсус җайланмалар;

9) мобиль сәүдә объекты – товарларны әзерләү, кую, демонстрацияләү, сатып алучыларга хезмәт күрсәтү һәм товарлар сатканда сатып алучылар белән исәп-хисап ясау өчен билгеләнгән махсус җиһазлар белән җиһазландырылган транспорт чарасыннан гыйбарәт сәүдә объекты. Әлеге объектларга механик транспорт чаралары һәм механик транспорт чаралары составында хәрәкәт итү өчен билгеләнгән транспорт чаралары (автомобильләр, автоприцеплар) керә.

## 3 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга һәм аларның тышкы күренешенә таләпләр

6. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасында (алга таба – урнаштыру схемасы) билгеләнгән урыннарда гамәлгә ашырыла.

7. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урам һәм юлларның кызыл линия чикләрендә урнаштырган очракта, аларны урнаштыру тротуар чикләрендә ныгытылган (асфальт түшәлгән) мәйданчыкта һәм тротуар буенча стационар булмаган сәүдә объектының кырый элементыннан йөри торган юл читенә кадәр 1,5 метрдан ким булмаган ирекле йөрү юлы калган шартларда гына мөмкин.

8. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштырганда, җәяүлеләр йөрү өчен комачауламый торган уңайлы автотранспорт юлы күздә тотылырга тиеш.

Товар һәм җиһазларны бушату һәм төяү автотранспортны тротуарга кертмичә гамәлгә ашыру таләп ителә.

9. Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән расланган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларының типовой проектларында шундый объектларны урнаштыру күздә тотылган очраклардан тыш, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары (урамга алып чыгып сату өчен күчереп йөртелә торган чаралардан тыш) янына суыткыч җиһазлар, өстәлләр, чатырлар һәм башка шундый объектлар урнаштыру рөхсәт ителми.

10. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларына таләпләр (тышкы күренеше, үлчәмнәре, мәйданы, конструктив схемасы һәм башка таләпләр) Башкарма комитет карары белән билгеләнгән типовой проектлар белән билгеләнә.

## 4 бүлек. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру һәм файдалану тәртибе

11. Гариза бирүчеләргә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы белән билгеләнгән урыннарда сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукы бирү

электрон аукционнар үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелә торган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясе әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә билгеләнә.

13. Сәүдә субъекты тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру (монтажлау) өчен нигез булып сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына төзелгән шартнамә һәм шартнамә буенча тулысынча түләү турында раслау тора.

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына шартнамә, әлеге Нигезләмәмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча, 180 көннән артмаган срокка төзелә.

14. Сәүдә субъекты тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларыннан файдалану өчен нигез булып, урнаштырылган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының шартнамәдә күрсәтелгән таләпләргә һәм типовой проектка туры килүе турында кабул итү комиссиясенең акты (алга таба – кабул итү комиссиясенең акты) тора.

Кабул итү комиссиясенең составы Башкарма комитет карары белән раслана.

15. Шартнамәдә күрсәтелгән таләпләргә һәм типовой проектка туры китереп урнаштырылган сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзелгән датадан башлап 15 (унбиш) көннән дә соңга калмый, тикшерү өчен кабул итү комиссиясенә күрсәтелергә тиеш. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын тикшерүне үткәрү өчен, сәүдә субъекты Башкарма комитетка тиешле мөрәҗәгать юллый.

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, мөрәҗәгать кергән вакыттан башлап 5 (биш) эш көне эчендә кабул итү комиссиясе тарафыннан тикшерелә.

16. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын тикшерү нәтиҗәләре буенча, тикшерү көненнән башлап 5 (биш) эш көне эчендә кабул итү комиссиясенең акты төзелә.

Кабул итү комиссиясе тарафыннан сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру шартнамәсе шартларын бозулар ачыкланган очракта, сәүдә субъекты 30 календарь көн эчендә кимчелекләрне бетерергә тиеш. Әгәр билгеләнгән срок тәмамланганнан соң кимчелекләр бетерелмәсә, Башкарма комитет шартнамәне өзү турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.

17. Кабул итү комиссиясе актыннан башка сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын эксплуатацияләү сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамәне өзү өчен нигез булып тора.

18. Стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын урнаштыру рөхсәт ителми:

1) инженерлык челтәрләренең саклау зонасында, тимер юл үткәргечләре һәм автомобиль эстакадалары астында, шулай ук җир асты җәяүлеләр кичүләренә керү (чыгу) урыннарыннан 5 метрлы саклау зонасында;

2) торак урын, бина тәрәзәләреннән, стационар сәүдә объектлары витриналарыннан 20 метрдан да кимрәк ераклыктагы биналар аркаларында, чәчәклекләрдә, балалар мәйданчыкларында, ял мәйданчыкларында, спорт мәйданчыкларында;

3) пассажир транспортының тукталыш пунктларында, шулай ук утырту мәйданчыклары чикләреннән 10 метрлы зонада;

4) мондый төзелеш (реконструкция) тәмамланганчы, автомобиль юлын төзү (реконструкцияләү) максатларында формалаштырылган җир участогы һәм башка объектларның проектлана торган линияләре чикләрендә;

5) җайга салынмый торган урамнарның һәм юлларның кисешкән һәм кушылган урыннарында күрү өчпочмагы чикләрендә;

6) тротуарларда, велосипед һәм җәяүлеләр юлларында;

7) җәяүлеләр кичүе чигенә кадәр 5 метрдан кимрәк ераклыкта;

8) агач кәүсәләренә, яктырткыч һәм башка баганаларга кадәр 3 метрдан кимрәк ераклыкта;

9) медиаэкран, суперсайт, пилларс, реклама стеласы, пилон фундаментына кадәр 5 метрдан кимрәк ераклыкта;

10) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру җәяүлеләр зоналарының киңлеген 3 метрдан кимрәк киметкән очракта, җәяүлеләр зоналарында;

11) законнарда билгеләнгән башка очракларда.

19. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты чикләреннән чыкмый торган, объектның киңлегенә һәм озынлыгына параллель урнашкан, биеклеге 5 сантиметрдан артмаган тимер-бетон балкалардан торган нигездә газонга урнаштыру рөхсәт ителә.

5 бүлек. Шартнамәнең гамәлдә булуын срогыннан алда туктату тәртибе

20. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамәнең гамәлдә булуы түбәндәге очракларда берьяклы тәртиптә срогыннан алда туктатыла:

1) сәүдә субъекты тарафыннан законда билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлеген туктату;

2) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә шартларын бозу;

3) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә буенча сәүдә субъекты тарафыннан рәттән ике айдан артык түләү кертелмәү;

4) Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түбәндәге карарларны кабул итү:

- автомобиль юлларын ремонтлау һәм (яки) реконструкцияләү зарурлыгы турында (сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының урнашуы күрсәтелгән эшләрне гамәлгә ашырырга комачаулаган очракта);

- урам-юл челтәрен үстерү, шәһәр җәмәгать транспорты тукталышларын урнаштыру, бордюрлар белән җиһазландыру, парковка урыннары оештыру белән бәйле максатлар өчен, сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты биләгән территориядән файдалану турында;

- региональ һәм муниципаль әһәмияткә ия капиталь төзелеш объектларын урнаштыру турында.

21. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамәнең гамәлдә булуы срогыннан алда туктатылган очракта, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә төзү буенча вәкаләтле орган, әлеге шартнамәнең гамәлдә булуын срогыннан алда туктату турында карар кабул иткән вакыттан башлап биш көнлек срокта, сәүдә субъектына тиешле белдерү кәгазе җибәрә.

22. Башкарма комитет инициативасы буенча сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамәнең гамәлдә булуы срогыннан алда туктатылган очракта, әлеге шартнамәне өзү турында белдерү кәгазен алган көннән башлап 5 (биш) көн эчендә, сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты үз хисабына сәүдә субъекты тарафыннан демонтажланырга тиеш.

23. Сәүдә субъекты тарафыннан Башкарма комитет адресына эшчәнлеген туктату турында гариза бирелгән очракта, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамәнең гамәлдә булуы берьяклы тәртиптә срогыннан алда туктатыла.

Шул ук вакытта, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын демонтажлау 5 (биш) календарь көн эчендә, сәүдә субъекты тарафыннан мөстәкыйль рәвештә үз хисабына гамәлгә ашырыла.

## 6 бүлек. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын демонтажлау

24. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты, шартнамәнең гамәлдәге срогы тәмамланган датадан башлап 5 (биш) календарь көн эчендә, сәүдә субъекты тарафыннан мәҗбүри рәвештә демонтажланырга тиеш.

25. Шартнамәнең гамәлдәге срогы чыкканнан соң яки шартнамәнең гамәлдә булуы срогыннан алда туктатылганда, шулай ук сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты билгеләнгән тәртиптәге рөхсәт документларыннан башка рөхсәтсез урнаштырылган очракта, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын демонтажлау сәүдә субъекты тарафыннан ирекле рәвештә үтәлмәгән очракта, Башкарма комитет карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булып тормаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибенә туры китереп, аны мәҗбүри рәвештә демонтажлау гамәлгә ашырыла.

## 7 бүлек. Йомгаклау һәм күчеш нигезләмәләре

26. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау, аңа үзгәрешләр кертү әлеге схеманы раслаганчы һәм аңа үзгәрешләр керткәнче урнаштыру хокукына шартнамә төзелгән сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарын яңадан карау өчен нигез була алмый.

27. Әлеге Нигезләмә шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар өлешендә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ Федераль законда билгеләнгән эксперимент үткәрү срогы дәвамында кулланыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына
шартнамә

Яр Чаллы шәһәре «____» __________ 20__ ел

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, ______________________________________________ нигезендә эш итүче ________________________________________________________________ исеменнән,
(вазыйфасы, Ф.И.А.и.)
алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы, бер яктан һәм ________________________________________________________________нигезендә эш итүче,
________________________________________________________________
________________________________________________________________
(хуҗалык итүче субъектның тулы исеме)
________________________________________________________________
________________________________________________________________ исеменнән,
(вазыйфасы, Ф.И.А.и.)
алга таба «Хуҗалык итүче субъект» дип аталучы, икенче яктан, ә бергә «Яклар» дип аталучылар
________________________________________________________________
________________________________________________________________ нигезендә
(Шартнамә төзүнең нигезе – сатулар нәтиҗәләре турында беркетмә күрсәтелә)

түбәндәгеләр турында Шартнамә төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Башкарма комитет Хуҗалык итүче субъектка Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ______________________________ гамәлгә ашыру өчен мәйданы _________кв.м. булган сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын (алга таба – Объект) урнаштыру хокукы бирә.

Объектның махсуслашуы ____________________________________________________.

Объект түбәндәге адреслар ориентиры буенча урнашкан _______________________.

Объектның урнашу урыны түбәндәге координатлар белән билгеләнгән: ___________
________________________________________________________________.

1.2. Әлеге Шартнамә Башкарма комитетның ______________________ номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы нигезендә төзелгән.

1.3. Әлеге шартнамәнең мөһим шартлары булып тора:

1) Хуҗалык итүче субъект тарафыннан әлеге шартнамәнең 1.1. пунктында күрсәтелгән шартларның үтәлүе;

2) кабул итү комиссиясенең акты булганда, хуҗалык итүче субъект тарафыннан объекттан файдалану;

3) Хуҗалык итүче субъект урнаштыруга хокукны түбәндәгеләр өчен файдаланмаска бурычлы:

- Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештән алынган яисә әйләнештә чикләнгән товарларны сату, мондый рөхсәт (лицензия) бирүгә вәкаләтле органның махсус рөхсәте (лицензиясе) нигезендә әйләнештә чикләнгән товарлар сату очракларыннан тыш;

- составында психотроп яки наркотик матдәләр һәм (яки) аларның прекурсорлары булырга мөмкин булган товарлар сату, мондый товарларны мондый рөхсәт (лицензия) бирүгә вәкаләтле органның махсус рөхсәте (лицензиясе) нигезендә сату очракларыннан тыш;

- азартлы уеннар оештыру һәм (яки) үткәрү белән бәйле эшчәнлекне, шул исәптән Интернет челтәре аша азартлы уеннар оештыру һәм (яки) үткәрү буенча өченче затларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

- алкогольле продукция, спиртлы эчемлекләр, шул исәптән аракы, шәраб, җиләк-җимеш шәрабы, ликерлы шәраб, күбекләнүчән шәраб (шампан шәрабы), шәраблы эчемлекләр, сыра һәм сыра нигезендә әзерләнә торган эчемлекләр, сидр, пуаре, әче бал; азык-төлек һәм азык-төлек булмаган чималдан ясалган спирт, шул исәптән денатурацияләнгән этил спирты, фармакопея статьялары буенча этил спирты, этил спиртының төп фракциясе (спирт җитештерү калдыклары), чимал спирты, шәраб, виноград, җиләк-җимеш, коньяк, кальвадос, виски дистиллятлары; әзер продукция күләменең 1,5 проценттан артыгын этил спирты тәшкил итүче спиртлы продукция; спиртлы азык-төлек продукциясе, шул исәптән шәраб материаллары, теләсә нинди эремәләр, эмульсияләр, суспензияләр, виноград сосласы, башка җиләк-җимеш сосласы, сыра сосласы; азык-төлек булмаган спиртлы продукция, шул исәптән денатуратлы спиртлы продукция, спиртлы парфюмер-косметик продукция, этил спиртын файдаланып җитештерелгән теләсә нинди эремәләр, эмульсия, суспензияләр, башка спиртлы продукция яки әзер продукция күләменең 1,5 проценттан артыгын этил спирты тәшкил итүче этил спирты җитештерүнең спиртлы калдыклары; азык-төлек чималыннан җитештерелгән этил спиртын кулланып яки кулланмыйча җитештерелгән алкоголь продукциясен һәм (яки) составында әзер продукция күләменең 0,5 процентыннан артыграгы этил спирты булган спиртлы азык-төлек продукциясен сату, шул исәптән агызып сату һәм куллану (эчү).

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Башкарма комитет хокуклы:

2.1.1. Хуҗалык итүче субъект тарафыннан әлеге Шартнамәнең шартларын һәм сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен җайга салучы муниципаль норматив хокукый актларның таләпләрен үтәүне контрольдә тотарга;

2.1.2. әлеге Шартнамәдә, гамәлдәге законнарда, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен җайга салучы муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә әлеге Шартнамә шартларын үтәүдән берьяклы тәртиптә баш тартырга;

2.1.3. Хуҗалык итүче субъект объектны ирекле тәртиптә демонтажлаудан һәм алып китүдән баш тарткан очракта, объектны мәҗбүри демонтажлауны гамәлгә ашырырга.

2.2. Башкарма комитет Хуҗалык итүче субъектка әлеге Шартнамәнең 1.1 пункты нигезендә адреслар ориентиры буенча урнашкан объектны урнаштыру хокукы бирергә бурычлы.

2.3. Хуҗалык итүче субъект әлеге Шартнамәдә, гамәлдәге законнарда, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен җайга салучы муниципаль норматив хокукый актларда каралган нигезләр буенча һәм тәртиптә, Башкарма комитетка 30 көн алдан язмача хәбәр итеп, әлеге Шартнамәнең шартларын үтәүдән срогыннан алда баш тартырга хокуклы.

2.4. Хуҗалык итүче субъект бурычлы:

2.4.1. килештерелгән проект нигезендә әлеге Шартнамәнең 1.1. пункты таләпләренә туры килә торган объектны урнаштыруны тәэмин итәргә һәм әлеге Шартнамә имзаланган көннән башлап 15 эш көне эчендә объектны урнаштыру турында кабул итү комиссиясенә хәбәр итәргә;

2.4.2. әлеге Шартнамә буенча түләүне үз вакытында һәм тулы күләмдә башкарырга;

2.4.3. Объектны әлеге Шартнамәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән билгеләнеше буенча файдаланырга;

2.4.4. Объект фасадына Хуҗалык итүче субъектның фирма исеме, урнашу урыны (адреслары), эш режимы күрсәтелгән элмә такта урнаштырырга. Элмә тактадагы мәгълүмат Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә урнаштырыла;

2.4.5. Объектның тышкы күренешен, аның урнашу урынын һәм үлчәмнәрен килешенгән проект нигезендә билгеләнгән урнашу чоры дәвамында саклауны тәэмин итәргә;

2.4.6. тиешле шартнамәләр төзеп, санитар нормалар һәм кагыйдәләрне үтәүне, Объекттан файдалану нәтиҗәсендә барлыкка килгән чүп-чар һәм башка калдыкларны чыгаруны тәэмин итәргә;

2.4.7. әлеге Шартнамә буенча Хуҗалык итүче субъектка бирелгән хокукларга алар нәтиҗәсендә нинди дә булса авырлык китерә торган яки авырлык китерергә мөмкин шартнамәләр төземәскә һәм килешүләргә бармаска, аерым алганда, аларның башка затка күчүе (залог шартнамәләре, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукын яки аның өлешен юридик затның устав капиталына кертү һәм башкалар);

2.4.8. Объект урнашкан урынның пычрануына, чүпләнүенә юл куймаска;

2.4.9 кулланучылар хокукларын яклау турында Россия Федерациясе законнары, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләрен, шулай ук Россия Федерациясе законнары тарафыннан товарларның аерым төрләрен сатуга карата куелган таләпләрне үтәргә;

2.4.10. сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруны җайга салучы муниципаль норматив хокукый актларда каралган шартларны үтәргә;

2.4.11. Башкарма комитетка үз реквизитларың (исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта, факсимиль элемтә) үзгәрү турында биш көнлек срокта язма рәвештә хәбәр итәргә. Хуҗалык итүче субъект тарафыннан әлеге шартлар үтәлмәгән очракта, Башкарма комитет тарафыннан әлеге Шартнамәдә күрсәтелгән реквизитлар буенча җибәрелә торган хатлар һәм башка корреспонденция хуҗалык итүче субъектка җибәрелгән һәм аларны фактта алу-алмавына карамастан, аңа хәбәр ителгән (ул тиешле хатлар, корреспонденцияне алган) дип санала;

2.4.12. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамланган вакыттан башлап 10 көн эчендә, шулай ук әлеге Шартнамәне срогыннан алда өзгән очракта, объектны аның билгеләнгән урнашу урыныннан демонтажларга һәм объект янәшәсендәге территорияне беренчел халәткә китерергә.

## 3. Объектны урнаштыру өчен түләү

3.1. Объектны урнаштыруга хокук өчен түләү шартнамәнең барлык гамәлдә булу срогы өчен ______________________________ сум тәшкил итә;

3.1.1. Аена ______________ сум.

3.1.2. Шул ук вакытта, Хуҗалык итүче субъект тарафыннан аукционда катнашу өчен, __________ ел № __________ түләү турындагы документ нигезендә ________ (______________) сум күләмдәнә кертелгән задаток сатып алына торган хокук өчен түләү исәбенә кертелә.

3.2. Әлеге Шартнамә нигезендә түләү ай саен, узган айдан соң килә торган айның ______ числосына кадәр башкарыла.

3.3. Шартнамә буенча түләүне күчерү түбәндәге реквизитлар буенча башкарыла: ______________________________.

3.4. Хуҗалык итүче субъект Шартнамә буенча хокук бәясен түләүдән баш тарткан яки читләшкән очракта, ул Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

3.5. Шартнамә буенча хокук бәясен түләү срокларын бозган очракта, фактта түләгәнгә кадәр яки әлеге Шартнамәне өзгәнгә кадәр, Хуҗалык итүче субъект Башкарма комитетка срогы чыккан һәр календарь көн өчен түләнмәгән сумма күләменнән 0,1% исәбеннән пеня түли. Әлеге Шартнамә Хуҗалык итүче субъектның Шартнамә буенча йөкләмәләрен бозу нәтиҗәсендә өзелсә, әлеге Шартнамәне өзү Хуҗалык итүче субъектны пенялар түләүдән азат итми.

3.6. Хуҗалык итүче субъект тарафыннан әлеге Шартнамәнең шартлары бозылу әлеге Шартнамәнең срогыннан алда өзелүенә китергән очракта, әлеге Шартнамәнең 3.1 пунктында билгеләнгән түләү суммасы Хуҗалык итүче субъектка кире кайтарылмый.

## 4. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы

4.1. Әлеге Шартнамә аны имзалаган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ________ кадәр гамәлдә була.

4.2. Әлеге Шартнамәнең гамәлдә булуы әлеге Шартнамәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән датадан соң килә торган көннән башлап туктатыла. Әлеге Шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамлану Якларны әлеге Шартнамәнең гамәлдә булуы тәмамлану вакытына үтәлмәгән барлык йөкләмәләрне тулысынча үтәүдән азат итми.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, Яклар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.

5.2. Объектны урнаштырмаган очракта, Хуҗалык итүче субъект әлеге Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәүдән азат ителми.

5.3. Хуҗалык итүче субъект тарафыннан Шартнамәнең 2.4.12. пунктында каралган таләпләр үтәлмәгән очракта, 20 мең сум күләмендә штраф билгеләнә;

5.4. Форс-мажор хәлләр килеп чыккан очракта, Яклар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Шартнамә буенча йөкләмәләрдән азат ителә.

## 6. Шартнамәне өзү

6.1. Әлеге Шартнамә суд карары буенча яки Шартнамә ягының граждан законнары нигезендә Шартнамәне үтәүдән берьяклы баш тартуына бәйле рәвештә өзелергә мөмкин.

6.2. Башкарма комитет әлеге Шартнамәне үтәүдән срогыннан алда, берьяклы тәртиптә түбәндәге нигезләр буенча баш тартырга хокуклы:

6.2.1. җирле үзидарә органы тарафыннан җир участогын түбәндәгеләргә бәйле азат итү турында карарлар кабул ителү:

- автомобиль юлларын ремонтлау һәм (яки) реконструкцияләү зарурлыгы (Объектның урнашуы күрсәтелгән эшләрне гамәлгә ашырырга комачаулаган очракта);
- автомобиль юлларын җиһазландыру элементларының саклагыч юл корылмаларын урнаштыру буенча эшләр алып бару;
- линия объектларын яки муниципаль әһәмияткә ия капиталь төзелеш объектларын урнаштыру;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча.

6.2.2. әлеге Шартнамәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән тәртиптә һәм срокларда Хуҗалык итүче субъект тарафыннан әлеге Шартнамә буенча ике ай рәттән түләү кертелмәү;

6.2.3. Хуҗалык итүче субъектның закон белән билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлеген туктатуы;

6.2.4. Хуҗалык итүче субъектның салым һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычлары ачыклану;

6.2.5. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка очракларда.

6.3. Әлеге Шартнамәне үтәүдән берьяклы тәртиптә баш тарткан очракта, Башкарма комитет Хуҗалык итүче субъектка язмача белдерү җибәрә. Күрсәтелгән белдерү кәгазе җибәргән вакыттан башлап 30 календарь көн узгач, әлеге Шартнамә өзелгән дип саналачак.

Бу очракта әлеге Шартнамә, әлеге белдерү кәгазендә күрсәтелгән датадан башлап, Хуҗалык итүче субъект тарафыннан җитешсезлек бетерелмәгән очракта белдерү кәгазендә билгеләнгән срокта өзелгән дип санала.

6.4. Шартнамә өзелгәннән соң, Объект хуҗалык итүче субъект тарафыннан, шартнамәдә күрсәтелгән нигезләр буенча һәм тәртиптә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә һәм тәртиптә демонтажланырга тиеш.

6.5. Объектны демонтажлау, шулай ук әлеге Шартнамәне срогыннан алда өзгән очракта, Шартнамәнең гамәлдә булу срогы тәмамланган вакыттан башлап 10 көн эчендә, Хуҗалык итүче субъект тарафыннан ирекле тәртиптә үз акчалары хисабына башкарыла.

Хуҗалык итүче субъект тарафыннан объектны ирекле тәртиптә демонтажлау 10 көн эчендә башкарылмаган очракта, Башкарма комитет, Башкарма комитет карары белән билгеләнгән тәртип нигезендә, тотылган чыгымнарны соңыннан Хуҗалык итүче субъект хисабыннан компенсацияләп, объектны мәҗбүри демонтажлауны гамәлгә ашыра.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Әлеге Шартнамәдә җайга салынмаган мәсьәләләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә хәл ителә.

7.2. Әлеге Шартнамәдән яки аңа бәйле рәвештә килеп чыккан теләсә нинди бәхәсләр яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителә, ә килешүгә ирешмәгән очракта, билгеләнгән тәртиптә судта карап тикшерүгә тапшырыла.

7.3. Әлеге Шартнамә бер үк юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә - Якларның һәркайсына берәр итеп төзелде.

## 8. Якларның реквизитлары һәм имзалары

| Башкарма комитет | Хуҗалык итүче субъект |
| --- | --- |
| «Татарстан Республикасы<br>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге<br>Башкарма комитеты» МКУ<br>423805, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт<br>Яр Чаллы шәһәре,<br>Татарстан Республикасы<br><br>______________________________ | |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын
урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен
билгеләү методикасы

1. Әлеге Методика сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен (алга таба - лот) билгеләү максатында эшләнде.

2. Электрон аукционга куела торган лотның башлангыч (минималь) бәясе дигәндә вәкаләтле орган лотны сатарга әзер булган минималь бәя аңлашыла.

3. Лотның башлангыч (минималь) бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

НЦЛ = (Спкс x Ккс x Кп x Sоб)/12 x Нвр (сум), монда:

НЦЛ - лотның башлангыч бәясе (сум);

Спкс - сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының мәйданы буенча җир участогының кадастр бәясе күрсәткеченең уртача чагыштырма зурлыгы (сум);

Ккс – җир салымы ставкасы (%) (Шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 9 ноябрендә 11/6 номерлы Карары белән расланган);

Кп - сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары өчен кулланыла торган коэффициент - 80;

Sоб - сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының мәйданы (кв.м);

Нвр – стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруның һәр эшчәнлек төре өчен билгеләнгән норматив вакыты (ай).

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруның норматив вакытын бер айдан ким билгеләгәндә, лотның югарыда күрсәтелгән формула буенча исәпләнә торган башлангыч бәясе 30 га бүленергә һәм урнаштыру көннәре санына тапкырланырга тиеш.

Күчереп йөртү маршрутында мобиль объектларны урнаштыру бәясен билгеләгәндә, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының мәйданы буенча җир участогының кадастр бәясе күрсәткеченең уртача арифметик зурлыгын файдаланырга кирәк, ул маршрутта барлык урнашу нокталарының Спкс күрсәткечләре суммасының шул ук маршрутта урнашу нокталары санына чагыштырмасы буларак билгеләнә.

Башкарма комитетның
2026 елның 13 гыйнварындагы
53 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру хокукына электрон аукцион
оештыру һәм үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына электрон аукцион оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре Уставы нигезендә эшләнде.

3. Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына аукцион катнашучылар составы буенча ачык булып тора һәм электрон аукцион (алга таба – электрон аукцион) формасында үткәрелә.

4. Электрон аукцион предметы булып сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукы (алга таба – лот) тора.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән электрон аукцион үткәрүне оештыруны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге (алга таба – Оештыручы) гамәлгә ашыра.

6. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән электрон аукцион үткәрүне Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге (алга таба – аукцион үткәрүгә Вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра.

7. Үткәрелгән ачык аукционнар нәтиҗәләре нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә төзүне һәм аларның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба – шартнамә төзү буенча вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра.

8. Составы Башкарма комитет карары белән раслана торган сатуларны оештыру һәм үткәрү буенча даими эшләүче комиссия (алга таба - комиссия) электрон аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерә, гариза бирүчеләрне электрон аукционда катнашучылар дип тану турында яки электрон аукционда катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итә, электрон аукционда җиңүчене билгели.

## 2 бүлек. Төп терминнар

9. Автоматлаштырылган система (АС) – электрон мәйданчык операторының аппарат-программа комплексы.

10. Аккредитация – гариза бирүчегә оператор регламенты таләпләре нигезендә операторның АС ябык өлешендә эшләү мөмкинлеге бирү.

11. Блокадалаучы субсчет – гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын тәэмин итү максатында электрон мәйданчык операторының исәп-хисап счетына күчерелгән акчаларын блокадалау өчен файдаланыла торган гариза бирүче счетының субсчеты.

12. Шартнамә – электрон аукцион йомгаклары буенча яки башлангыч бәя буенча Россия Федерациясе Граждан кодексында, башка федераль законнарда һәм муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты һәм сәүдә субъекты тарафыннан төзелгән сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыру хокукына шартнамә.

13. Мәйданчык операторы – Россия Федерациясе территориясендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган, сайлап алынган электрон мәйданчыгы булган һәм анда электрон аукционнар үткәрүне тәэмин итүче, аның эшләп торуы өчен кирәкле программа-аппарат чараларына ия булган, оештыру-хокукый формасына, милекчелек формасына, урнашу урынына һәм капитал барлыкка килү урынына бәйсез юридик зат.

14. Рәсми сайт – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге сайты http://nabchelny.ru/.

15. Электрон аукционда җиңүче – әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыру хокукының иң югары бәясен тәкъдим иткән зат.

16. Заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү беркетмәсе – комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган, гариза бирүчене электрон аукционда катнашучы дип тану һәм сәүдә сессиясенә кертү турында мәгълүматлар булган беркетмә.

17. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсе – электрон аукцион буенча сәүдә сессиясе үткәргәннән соң электрон мәйданчык операторы тарафыннан төзелгән беркетмә.

18. Йомгак ясау беркетмәсе – комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган, катнашучыны электрон аукционда җиңүче дип тану турында һәм электрон аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүматлар булган беркетмә.

19. Гариза бирүче – оештыру-хокукый формасына, милекчелек формасына, урнашу урынына һәм капитал барлыкка килү урынына бәйсез юридик зат яки шәхси эшмәкәр, шулай ук шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат.

20. Электрон аукционда катнашучы – электрон аукционда катнашуга заявка биргән һәм комиссия тарафыннан электрон аукционда катнашучы дип танылган гариза бирүче.

21. Электрон документ – мәгълүматны электрон-цифрлы рәвештә бирә торган документ, шул исәптән кәгазь документларның сканерланган версияләре.

22. Электрон цифрлы имза – электрон рәвештәге башка мәгълүматка (имзалана торган мәгълүматка) тоташтырыла торган яки әлеге мәгълүмат белән башкача бәйле булган һәм мәгълүматны имзалаучының затын билгеләү өчен файдаланыла торган электрон рәвештәге мәгълүмат.

## 3 бүлек. Аукцион үткәрүгә вәкаләтле орган, шартнамә төзү буенча вәкаләтле орган оештыручысының хокуклары

23. Оештыручы хокуклы:

1) аукцион үткәрү турында карар кабул итәргә;

2) лотларның составын билгеләргә;

3) Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясен билгеләү методикасы («Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта) нигезендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясен билгеләргә;

4) заявканы һәм хәбәр әзерләү өчен кирәкле документларны әзерләргә;

5) хәбәрне әзерләргә һәм расларга;

6) заявкалар кабул итү тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча, хәбәргә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә;

7) заявкалар кабул итү тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча, электрон аукцион үткәрүдән баш тартырга;

8) Россия Федерациясе законнары, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 өлеше нигезендә шундыйларга кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арасында гына электрон аукцион үткәрү турында таләп куярга;

9) заявканы тәэмин итү күләмен билгеләргә;

10) әлеге Нигезләмәдә каралган һәм Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган башка кирәкле функцияләрне башкарырга.

24. Аукцион үткәрүгә вәкаләтле орган хокуклы:

1) заявкаларны кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын, электрон аукцион үткәрү датасын билгеләргә;

2) электрон аукцион үткәрү турында хәбәрне, электрон аукцион үткәрүдән баш тарту турында хәбәрне электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта бастырып чыгарырга;

3) хәбәргә кертелә торган үзгәрешләрне электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта урнаштырырга;

4) мөрәҗәгать итү датасыннан башлап ике эш көне эчендә, запрос буенча гариза бирүчегә хәбәр нигезләмәләренә аңлатма җибәрергә;

5) электрон аукцион нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта урнаштырырга. Гариза бирүче — электрон аукционда катнашучы электрон мәйданчыкта, рәсми сайтта урнаштырылган хәбәр, аңа кертелгән үзгәрешләр белән танышмаган очракта, аукцион үткәрүгә вәкаләтле орган җаваплы булмый.

25. Шартнамә төзү буенча вәкаләтле орган хокуклы:

1) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары урнаштыру хокукына шартнамәләр төзергә;

2) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары урнаштыру хокукына шартнамә шартларының үтәлешенә контрольне гамәлгә ашырырга;

3) җиңүченең задатогын Башкарма комитет хисабына күчерүне гамәлгә ашырырга;

4) әлеге Нигезләмәдә каралган һәм Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган башка кирәкле функцияләрне башкарырга.

## 4 бүлек. Электрон мәйданчык операторының вәкаләтләре

26. Электрон мәйданчык операторы хокуклы:

1) әлеге Нигезләмә нигезендә электрон мәйданчык операторы хезмәтләре күрсәтергә;

2) Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә электрон мәйданчыкның эшкә сәләтен һәм эшләвен тәэмин итәргә.

27. Электрон мәйданчык операторы бурычлы:

1) электрон аукцион үткәрүнең өзлексезлеген, электрон аукцион үткәрү өчен файдаланыла торган техник һәм программа чаралары эшенең ышанычлылыгын, электрон аукцион тәмамлану вакытына бәйсез рәвештә, аукционда катнашучыларның анда катнашуга бертигез мөмкинлеген тәэмин итәргә;

2) электрон мәйданчыкта аккредитация расланган вакыттан башлап, гариза бирүчегә электрон аукционда катнашуга кертелүне тәэмин итәргә;

3) электрон аукционнар үткәрү өчен, Башкарма комитетка шәхси кабинетка керүне тәэмин итәргә;

4) Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә, электрон мәйданчыкта электрон документлардан файдалануны тәэмин итәргә;

5) аукционда катнашуга заявкаларны (алга таба – заявкалар) һәм аларга теркәлгән документларны кабул итәргә;

6) заявкаларны исәпкә алуны һәм теркәүне башкарырга;

7) катнашучыларның заявкаларына кагылышлы кабул ителгән карарлар турында аларга хәбәр итәргә;

8) электрон аукцион үткәрү беркетмәсе төзергә;

9) гариза бирүчеләр, аукционда катнашучылар һәм җиңүчеләр белән заявканы тәэмин итүне кабул итү һәм кире кайтару буенча исәп-хисаплар ясарга;

10) электрон мәйданчыкта техник җитешсезлекләр килеп чыккан очракта, шундый җитешсезлекләр турында, шулай ук яңа аукцион датасы һәм вакыты турында барлык гариза бирүчеләргә, электрон аукционда катнашучыларга һәм Башкарма комитетка хәбәр итәргә.

28. Әлеге Нигезләмәдә каралган һәм Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган башка кирәкле функцияләрне башкарырга.

## 5 бүлек. Комиссиянең вәкаләтләре

29. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

1) теркәлгән документлар белән бергә электрон аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерергә;

2) гариза бирүчеләрне электрон аукционда катнашучылар дип тану турында яки гариза бирүчеләрне электрон аукционда катнашуга кертүне кирү кагу турында карарлар кабул итәргә һәм заявкаларның беренче карап тикшерү беркетмәсен рәсмиләштерергә;

3) электрон аукционда җиңүчене билгеләргә;

4) электрон аукционга йомгак ясау беркетмәсен рәсмиләштерергә;

5) әлеге Нигезләмәдә каралган һәм Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган башка кирәкле функцияләрне башкарырга.

30. Комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 50 проценты катнашса, комиссия үз функцияләрен гамәлгә ашырырга хокуклы.

## 6 бүлек. Гариза бирүчеләргә – электрон аукционда катнашучыларга таләпләр

31. Оештыру-хокукый формасына, милек формасына, урнашу урынына, шулай ук капитал барлыкка килү урынына бәйсез, электрон мәйданчыкта аккредитация үткән юридик зат яки шәхси эшмәкәр, шулай ук шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри

керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат гариза бирүче булырга мөмкин.

32. Гариза бирүчеләр - электрон аукционда катнашучылар Россия Федерациясе законнарында шундый катнашучыларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш, шул исәптән:

1) юридик затның, шәхси эшмәкәрнең ликвидацияләнү факты булмау һәм юридик затны, шәхси эшмәкәрне, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затны банкрот дип тану һәм конкурс производствосы ачу турында арбитраж суд карарлары булмау;

2) заявка биргән көнгә Россия Федерациясенең Хокук бозулар турында кодексында каралган тәртиптә эшчәнлекне туктату факты булмау.

7 бүлек. Электрон аукционда катнашу өчен заявканы тәэмин итү һәм электрон аукцион адымы

33. Гариза бирүче, электрон аукционда заявка бирү өчен, электрон мәйданчыкта блокадалаучы субсчетка акча күчерә:

1) заявканы тәэмин итү сыйфатында – стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясеннән 100 процент күләмендә;

2) электрон аукционда катнашу өчен түләү сыйфатында – лотның башлангыч бәясенә бәйле рәвештә дифференцияләнеп, оператор тарафыннан билгеләнгән һәм электрон аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән күләмдә.

34. Электрон аукцион адымы сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясенең 5 проценты күләмендә билгеләнә.

8 бүлек. Электрон аукцион үткәрү турында хәбәр

35. Аукцион үткәрүгә вәкаләтле орган әлеге Нигезләмә нигезендә, аны үткәргәнче кимендә утыз көн алдан электрон аукцион турындагы хәбәрне http://sale.zakazrf.ru адресы буенча электрон мәйданчыкта урнаштыруны гамәлгә ашыра.

36. Хәбәрдә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) сатуларны оештыручының исеме, урнашу урыны һәм элемтә телефоны номеры;

2) гариза бирүчеләргә таләпләр;

3) объектның төре һәм мәйданы, аны урнаштыру урыны һәм срогы, махсуслашуы, сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясе турында мәгълүматны үз эченә алган лот (лотлар) турында мәгълүматлар;

4) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының типовой проекты яки, булган очракта, күчмә корылмаларга таләпләр;

5) заявка эчтәлегенә, формасына, аны рәсмиләштерүгә һәм составына карата таләпләр;

6) заявканы тәэмин итү күләме, аны кертү срогы һәм тәртибе;

7) заявкаларны кабул итә башлау һәм аның тәмамлану датасы һәм вакыты;

8) заявкаларны карап тикшерү датасы һәм вакыты;

9) заявкаларны кире алу тәртибе һәм срогы;

10) электрон аукцион үткәрү датасы, вакыты һәм тәртибе;

11) электрон аукцион үткәрелгәннән соң шартнамә төзү срогы;

12) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә проекты.

37. Оештыручы хәбәргә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Электрон аукцион предметын үзгәртү рөхсәт ителми. Аукцион үткәрүгә вәкаләтле орган,

шундый карар кабул ителгән көннән соң бер көн эчендә, ләкин заявкаларны кабул итү тәмамлану көненә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмый, күрсәтелгән үзгәрешләрне электрон мәйданчыкта һәм рәсми сайтта урнаштыра.

38. Оештыручы электрон аукцион үткәрүне кире кагу турында карар кабул итәргә хокуклы. Аукцион үткәрүгә вәкаләтле орган, шундый карар кабул ителгәннән соң бер көн эчендә, ләкин заявкаларны кабул итү тәмамлану көненә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмый, электрон аукцион үткәрүне кире кагу турындагы хәбәрне электрон мәйданчыкта урнаштыра.

## 9 бүлек. Заявкаларны кабул итү тәртибе

39. Электрон аукционда катнашуга заявкалар бирү бары тик электрон мәйданчыкта аккредитация алган затлар тарафыннан гына гамәлгә ашырыла. Гариза бирүченең электрон аукционнарда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счетында, аның тарафыннан бирелгән заявкаларны тәэмин итү өчен җитәрлек акчасы булганда электрон аукционда катнаширга мөмкин.

40. Гариза бирүче тарафыннан электрон аукционга заявка ике өлештә һәм заявка бирелә торган һәр лотка карата хәбәрдә билгеләнгән форма буенча һәм срокларда бирелә. Заявканың һәр өлеше электрон цифрлы имза белән имзалана, ике өлеше дә бер үк вакытта бирелә.

41. Заявканың беренче өлеше түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) хәбәр нигезендә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыру хокукын сатып алуга ризалык;

2) электрон аукцион үткәрү датасы һәм электрон аукцион номеры турында мәгълүмат.

42. Заявканың икенче өлеше түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) гариза бирүче турында мәгълүматлар, шул исәптән юридик затның исеме һәм урнашу урыны яисә шәхси эшмәкәрнең яки шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, почта адресы, ИНН, заявканың тәэмин ителешен кире кайтару һәм (яки) шартнамә төзү өчен банк реквизитлары, элемтә телефоны номеры;

2) сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштырганда, хәбәрдә күрсәтелгән мәҗбүри шартларны үтәүгә ризалык;

3) электрон аукцион үткәрү турындагы хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан алынган өземтә күчермәсе; электрон аукцион үткәрү турындагы хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан алынган өземтә күчермәсе; электрон аукцион үткәрү турындагы хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә алынган, юридик затның яки физик затның шәхси эшмәкәр буларак дәүләти теркәлү турында тиешле дәүләт законнары нигезендә рус теленә тәрҗемә ителгән документларның күчермәсе (чит ил затлары өчен);

4) затның гариза бирүче – юридик зат исеменнән эшләр башкаруга вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе (физик затка ышаныч язуыннан башка гариза катнашучы исеменнән эш итәргә хокук бирә торган, физик затны вазыйфага билгеләү турында яки сайлау турында карар яисә билгеләү турында боерык күчермәсе (алга таба – җитәкче). Катнашучы исеменнән башка зат эш иткән очракта, заявкада, гариза бирүче исеменнән эш итү өчен, гариза бирүченең мөһере (булганда) белән расланган һәм гариза бирүченең җитәчесе (юридик затлар өчен) яки җитәкченең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган ышаныч язуының күчермәсе булырга тиеш. Күрсәтелгән ышаныч язуы гариза бирүченең җитәкчесенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган очракта, заявкада шул затның вәкаләтләрен раслаучы документның күчермәсе дә булырга тиеш;

5) юридик затлар өчен: гариза бирүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (ИНН, ОГРН яки юридик затны салым органында исәпкә кую турындагы язу бите, уставның барлык битләре), шәхси эшмәкәрләр өчен: паспортның барлык битләренең күчермәләре, ИНН, ОГРН яки физик затны салым органында шәхси эшмәкәр сыйфатында исәпкә кую турындагы язу бите, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат өчен: паспортның барлык битләренең күчермәләре, ИНН, салым органыннан физик затның һөнәри керемгә салым түләүче категориясенә кертелүен раслый торган документ;

6) гариза бирүченең – юридик затның ликвидацияләнүе турында карар булмау, гариза бирүчене – юридик затны, шәхси эшмәкәрне, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затны банкрот дип тану турында һәм конкурс производствосы ачу турында арбитраж суд карары булмау турында, Россия Федерациясенең Хокук бозулар турында кодексында каралган тәртиптә гариза бирүченең эшчәнлеген туктату турында карарлар булмау турында гариза.

43. Заявка керү, электрон аукционда катнашуга заявканы тәэмин итү күләмендәге акчаларга карата, гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счеты буенча операцияләрне блокадалау йөкләмәсе булып тора.

44. Гариза бирүче электрон аукционның һәр предметына (лотка) карата электрон аукционда катнашуга бер генә заявка бирергә хокуклы.

45. Электрон мәйданчык операторы түбәндәге очракларда заявкалар кабул итүне кире кага:

1) электрон аукционда катнашуга заявканы электрон документлар әйләнеше таләпләрен бозып бирү;

2) электрон аукционда катнашуга заявка биргән гариза бирүченең электрон аукционнарда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счетында электрон аукционда катнашуга заявкасын тәэмин итәрлек күләмдә акчасы булмау;

3) гариза бирүче тарафыннан алдан бирелгән заявкалары кире алынмаган шартларда, бер үк гариза бирүче тарафыннан шул ук бер лотка карата электрон аукционда катнашуга ике яки берничә заявка бирелү. Бу очракта, гариза бирүчегә әлеге лотка карата электрон аукционда катнашуга бирелгән барлык заявкалары да кире кайтарыла;

4) заявкалар бирү срогы тамамланганнан соң электрон аукционда катнашуга заявка алу;

5) гариза бирүчедән электрон аукционда катнашуга аккредитация кагыйдәләре бозылган заявка алу.

Гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын кире кагу өчен күрсәтелгән нигезләр исемлеге тулы булып тора.

46. Гариза бирүче заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр теләсә кайсы вакытта электрон аукционда катнашуга заявкасын кире алырга хокуклы.

47. Электрон аукционда катнашуга заявка бирү, электрон аукцион йомгаклары буенча катнашучыны җиңүче дип таныган һәм аңа шартнамә төзү хокукы бирелгән очракта, гариза бирүченең электрон аукционда катнашуын тәэмин итү буенча операцияләр үткәрү өчен ачылган счетындагы акчаларны электрон аукционда катнашу өчен түләү сыйфатында исәптән чыгаруга ризалыгы булып тора.

48. Оператор, катнашуга бирелгән зявкаларның икенче өлешен карап тикшерү өчен, Башкарма комитет адресына җибәргәнче үзара эш итүче якларга карата, электрон аукционда катнашуга заявка биргән гариза бирүчеләр мәгълүматларының конфиденциальлеген тәэмин итә.

49. Электрон аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамлануга бер генә заявка бирелгән яки бер заявка да бирелмәгән очракта, электрон аукцион үтмәгән дип таныла.

50. Электрон аукционда катнашуга заявкаларны бирү, кире кайтару һәм кире алу нәтиҗәләре буенча электрон аукцион заявкалары реестрында бер генә заявка булган очракта, заявканың беренче өлеше турындагы мәгълүматлар белән берьюлы заявканың икенче өлеше дә җибәрелә.

## 10 бүлек. Заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү

51. Комиссия заявкаларның беренче өлешен карап тикшерүне башкара, әлеге тикшерү срогы заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

52. Заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү тәмамланганнан соң, комиссия заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү буенча язмача беркетмә формалаштыра, ул комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Күрсәтелгән беркетмә һәр заявкага карата рөхсәт итү яисә рөхсәт итүне кире кагу турында карарларны үз эченә ала, беркетмә имзаланган көннең икенче көненнән дә соңга калмый операторга җибәрелә һәм электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

53. Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе оператор тарафыннан электрон мәйданчыкта урнаштырылган вакыттан соң бер сәгать эчендә, барлык гариза бирүчеләргә дә заявкаларына карата кабул ителгән карарлар турында белдерү язуы җибәрелә.

54. Түбәндәге очракларда электрон аукцион үтмәгән дип танылa:

1) заявкалар бирү срогы тәмамлануга бер генә заявка бирелү;

2) заявкалар бирү срогы тәмамлануга бер заявка да бирелмәү;

3) комиссия тарафыннан барлык гариза бирүчеләрне дә электрон аукционда катнашуга кертүне кире кагу турында карар кабул итү.

55. Хәбәрдә ике һәм күбрәк лот каралган очракта, шундый карар кабул ителгән лотларга карата электрон аукцион үтмәгән дип таныла.

56. Әлеге Нигезләмәнең 54 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән сәбәп буенча электрон аукцион үтмәгән дип танылган очракта, Башкарма комитет яңа электрон аукцион үткәрү турында игълан итәргә хокуклы. Яңа электрон аукцион үткәрү турында игълан ителгән очракта, Башкарма комитет аның шартларын үзгәртергә хокуклы.

57. Гариза бирүче, комиссия тарафыннан заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү турында беркетмә рәсмиләштерелгәннән соң, электрон аукционда катнашучы статусы ала.

## 11 бүлек. Электрон аукцион оештыру һәм үткәрү

58. Электрон мәйданчыкта электрон аукцион хәбәрдә күрсәтелгән көнне үткәрелә.

59. Электрон аукцион үткәрелә башлаганнан соң катнашучы лот бәясе турында үз тәкъдимнәрен бирергә хокуклы.

60. Катнашучы электрон аукционның башка катнашучысы тарафыннан тәкъдим ителгән бәягә тигез лот бәясе турында тәкъдим керткән очракта, лот бәясе турында башка тәкъдимнәрдән алдарак кергән тәкъдим иң яхшысы дип таныла.

61. Электрон мәйданчыкта аукцион адымы сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясенең 5 (биш) процентын тәшкил итә.

62. Электрон аукцион үткәрү вакытында катнашучы тарафыннан бирелә торган лот турындагы һәр тәкъдим электрон цифрлы имза белән имзалана.

63. Электрон аукцион үткәргәндә лот бәясе турындагы тәкъдим тиенәнә кадәр төгәллек белән билгеләнә.

64. Электрон аукционда катнашучылар, агымдагы максималь тәкъдимне аукцион адымы зурлыгына арттыруны күздә тотучы лот бәясе турында тәкъдимнәр бирәләр.

65. Иң югары лот бәясен тәкъдим иткән катнашучы аукционда җиңүче дип таныла.

66. Соңгы тәкъдимне кабул иткәннән соң яки электрон аукцион башланганнан соң ун минут эчендә лот бәясе турында бер тәкъдим дә бирелмәгән очракта, әлеге лот буенча электрон аукцион автомат рәвештә тәгәлләнә.

67. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсе, электрон аукцион тәмамланганнан соң 30 (утыз) минут эчендә оператор тарафыннан электрон мәйданчыкта урнаштырыла.

68. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсендә электрон мәйданчык адресы; электрон аукцион датасы, башлану һәм тәмамлану вакыты; сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясе; сезонлы стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыру хокукының бәясе (лот бәясе) турында электрон аукционда катнашучылар тарафыннан бирелгән һәм, тәкъдимнәр кергән вакытны күрсәтеп, лот бәясе турында тиешле тәкъдимне ясаган электрон аукционда катнашучылар тарафыннан тапшырылган электрон аукционда катнашуга заявкаларга бирелгән тәртип номерлары күрсәтелеп, кими бару тәртибендә ранжирланган барлык максималь тәкъдимнәр күрсәтелә.

69. Электрон аукцион башланганнан соң ун минут эчендә электрон аукционда катнашучыларның берсе дә лот бәясе турында тәкъдим кертмәгән очракта, электрон аукцион үтмәгән дип таныла. Күрсәтелгән вакыт тәмамланганнан соң утыз минут эчендә оператор электрон аукцион үтмәгән дип тану турында беркетмәне (электрон мәйданчык адресын, электрон аукцион датасын, башлану һәм тәмамлану вакытын, лотның башлангыч (минималь) бәясен күрсәтеп) электрон сәүдә мәйданчыгында урнаштыра һәм аны вәкаләтле органга җибәрә.

## 12 бүлек. Электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү һәм йомгак ясау

70. Электрон аукцион үткәрү беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырганнан соң бер сәгать эчендә, оператор электрон аукцион үткәрү беркетмәсен, электрон аукционда катнашучылар тарафыннан бирелгән электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлешен һәм аккредитацияләнгән катнашучылар реестрындагы мәгълүматларны Башкарма комитетка җибәрә.

71. Комиссия электрон аукционда катнашуга заявкаларның икенче өлеше хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килүне карап тикшерә.

72. Заявкаларның икенче өлешен, шулай ук аккредитацияләнгән катнашучылар реестрындагы мәгълүматларны карап тикшерүнең гомуми срогы электрон аукцион үткәрү беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырган көннән соң өч эш көненнән артырга тиеш түгел.

73. Комиссия заявкаларның икенче өлешен, электрон аукционда катнашуга 2 (ике) заявканың хәбәрдә каралган таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгәнче карап тикшерә. Заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционда катнашучы тарафыннан бирелгән заявкадан башлана һәм электрон аукционда катнашуга заявкаларның кими бару тәртибендә ранжирлануын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

74. Заявкаларның хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгән очракта, шулай ук аукционның барлык катнашучылары тарафыннан бирелгән заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү нигезендә, бердән артык заявканың күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул ителгән очракта, комиссия тарафыннан электрон аукционга йомгак ясау беркетмәсе рәсмиләштерелә һәм заявкаларны карап тикшерү тәмамланган көнне комиссиянең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

75. Беркетмә, ранжирланган һәм хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килү турында карар кабул итүгә мөнәсәбәтле электрон аукционда катнашуга заявкаларның тәртип номерлары турында мәгълүматларны, электрон аукционда катнашуга заявкаларының икенче өлеше карап тикшерелгән катнашучылар турындагы мәгълүматларны, кабул ителгән карарны дәлилләп, заявкаларның хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турындагы карарны, заявканың хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки туры килмәве турында комиссиянең һәр әгъзасының карары турындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

76. Иң югары лот бәясен тәкъдим иткән һәм заявкасы хәбәрдә билгеләнгән таләпләргә туры килгән электрон аукцион катнашучысы электрон аукционда җиңүче дип таныла.

77. Электрон аукционда катнашуга бердәнбер заявка бирелү яисә бер генә гариза бирүче электрон аукционда катнашучы дип танылу сәбәпле электрон аукцион үткәрелмәгән дип танылган очракта, аукционны оештыручы хәбәрдә каралган шартларда, электрон аукционда катнашу өчен бердәнбер заявка биргән зат белән (күрсәтелгән заявка хәбәрдә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килгән очракта), шулай ук электрон аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат белән, электрон аукцион үткәрү турында хәбәрдә күрсәтелгән сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясенә тигез булган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының бәясе белән сезонлы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә төзергә тиеш.

78. Электрон аукционга йомгак ясау беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырган көннән соң биш эш көне эчендә, шартнамә төзү буенча вәкаләтле орган электрон аукционның шартнамә төзүгә мөнәсәбәтле катнашучысы тарафыннан тәкъдим ителгән лот бәясен кертү юлы белән төзелгән шартнамә проектын операторга җибәрә. Оператор кабул ителгән шартнамә проектын бер сәгать эчендә электрон аукционда җиңүчегә җибәрә.

79. Электрон аукционда җиңүче, шартнамә проектын алганнан соң биш эш көне эчендә, электрон мәйданчыкларның эш шартлары нигезендә, электрон аукционда катнашучы исеменнән эш итү хокукына ия затның көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган шартнамә проектын электрон мәйданчык операторына җибәрә. Оператор, бер сәгать эчендә, электрон аукционда җиңүчедән алынган шартнамәне Башкарма комитет адресына җибәрә.

80. Шартнамә төзү буенча вәкаләтле орган, өч эш көне эчендә, электрон мәйданчыкларның эш шартлары нигезендә, Башкарма комитет исеменнән эш итү хокукына ия затның көчәйтелгән электрон имзасы белән имзаланган шартнамәне операторга җибәрергә тиеш. Оператор бер сәгать эчендә шартнамәне электрон аукционда җиңүчегә җибәрә.

81. Әлеге Нигезләмәнең 80 пункты нигезендә, оператор тарафыннан электрон аукционда катнашучыга шартнамә җибәрелгәннән соң, шартнамә төзелгән дип санала. Шартнамәне теркәү шартнамә төзү буенча вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

82. Шартнамә төзелгән көннән башлап бер эш көне эчендә, оператор аукционда катнашуны тәэмин итү өчен блокадаланган акчаларга карата, электрон аукционның барлык катнашучыларының блокадалаучы субсчетлары буенча операцияләрне блокадалауны туктата. Шулай ук оператор, җиңүче дип танылган электрон аукционда катнашучының блокадалаучы субсчетыннан, аукционда катнашкан өчен түләү сыйфатында, әлеге Нигезләмәнең 33 пунктының 2 пунктчасында каралган күләмдә акчаларын ала.

83. Шартнамә төзелә:

1) электрон аукционда җиңүче белән;

2) аукционда җиңүче билгеләнгән срокта шартнамә төзүдән качарга тырышкан яки баш тарткан очракта – электрон аукционда җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгән лот бәясеннән соң иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционның башка катнашучысы белән;

3) заявкасы һәм документлары комиссия тарафыннан хәбәргә туры килә дип танылган бердәнбер гариза бирүче белән;

4) заявкаларның икенче өлешен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, комиссия тарафыннан бердәнбер катнашучы дип танылган электрон аукционда катнашучы белән.

84. Әлеге Нигезләмәнең 83 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән очракта, электрон аукционда җиңүче шартнамә төзү хокукын югалта һәм заявканың тәэмин ителеше аңа кире кайтарылмый, ә оператор тарафыннан Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты счетына күчерелергә тиеш була.

81. Әлеге Нигезнләәнең 83 пунктында күрсәтелгән затлар лот буенча шартнамә төзүдән качарга тырышкан очракта, әлеге лот буенча электрон аукцион үтмәгән дип таныла һәм вәкаләтле лотны сатуга кабат куярга хокуклы.

13 бүлек. Заявка тәэмин ителешен кире кайтару тәртибе

86. Заявкаларны тәэмин итү сыйфатында гариза бирүчеләр тарафыннан кертелгән акчалар оператор тарафыннан биш эш көне эчендә кире кайтарыла:

1) гариза бирүчеләргә – электрон аукцион үткәрүне кире кагу турындагы хәбәр электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән башлап;

2) заявкасын кире алу сәбәпле, гариза бирүчегә – заявкаларны кабул итү тәмамланган көнгә кадәр;

3) электрон аукцион үтмәгән дип танылган очракта, гариза бирүчеләргә – заявкаларның беренче өлешен карап тикшерү беркетмәсе электрон мәйданчыкта урнаштырылган көннән башлап;

4) электрон аукционда катнашучыларга – электрон аукцион йомгакларын чыгару беркетмәсен электрон мәйданчыкта урнаштырган көннән башлап, җиңүче һәм җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгәннән соң, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән катнашучыдан тыш;

5) электрон аукционда җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгәннән соң, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционда катнашучыга – җиңүче белән шартнамә төзелгәннән соң.

87. Электрон аукционда җиңүчене яки җиңүче тарафыннан тәкъдим ителгәннән соң, иң югары лот бәясен тәкъдим иткән электрон аукционда катнашучыны шартнамә төзүдән баш тарткан дип таныган очракта, әлеге катнашучылар тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 33 пунктының 1 пунктчасы нигезендә, заявкаларны тәэмин итү сыйфатында кертелгән акчалар кире кайтарылмый, ә оператор тарафыннан Башкарма комитет счетына күчерелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева